
№37 (13564) ШӘҺӘР ҺӘМ РАЙОН ГАЗЕТАСЫ 22 СЕНТЯБРЬ, 2023 ЕЛ

# ӘЛМӘТ ТАҢНАРЫ

Яңалыкларны **almet-rt.ru** сайтында һәм социаль челтәрдәге төркемнәребездә беренче булып укыгыз

16+

# Авыл «чика»сы кайда да сынатмый



Блогер Альбина Вәлиева турында язманы укыгыз:

6

28 СЕНТЯБРЯ с 10-00 до 18-00
ТЦ «Корона», ул. Герцена, 3в



Фабрика «Планета меха»
объявляет открытие мехового сезона!
*Качественно, красиво и недорого!*
*Кировская норка, пятигорский мутон из астрагана, каракуль, песец, енот. Турецкие дубленки. Мужские куртки, головные уборы и многое другое.*
Размеры от 46 до 74
Норка от 28000 т.р.
Мутон от 14000 т.р.
Каракуль от 23000 т.р.
Дубленки от 15000 т.р.
Все модели 2023 и 2024 г.
Акция* «Обмен старого на новое»
Реклама 16+
**Акция действует только 28 сентября*
Кредит на выгодных условиях до 3х лет без первого взноса. Кредит предоставляет КБ «Ренессанс Кредит» (ООО). Лицензия Банка России 3354 от 26.04.2013

28 СЕНТЯБРЯ, ТЦ «Корона», ул. Герцена, 3в
с 10-00 до 18-00



ВНИМАНИЕ: *камчатская и сахалинская вкусная, свежая красная икра из сортов горбуши, кеты, чавычи, кижуча, нерки, форели.*
Акция:*
1 банка - 300 руб.
2 банки - 500 руб.
5 банок - 1000 руб.
*Приходите, мы вас ждем!*
**Акция действует только 28 сентября*
Реклама

2024 елның I яртыеллыгына газета-журналларга язылу башланды



Илтеп бирү (почта аша):
- барлык почта бүлекчәләрендә
- Дәүләт хезмәтләре порталында

824,40 сум

Килеп алу (альтернатив пунктлар):
- газета редакциясе офисында (Пушкин урамы, 64)
- Үзәк китапханәдә (Сөләйманова урамы, 20)
- Түбән Мактама китапханәсендә (Некрасов урамы, 18)

500 сум

Белешмә өчен телефон: 8(8553) 44-05-88.

Реклама 16+

*«Знамя труда» һәм «Әлмәт таңнары» газеталарына үзегез дә язылыгыз, әти-әниләрегезне, әби-бабайларыгызны яздырырга да онытмагыз.*





ЛЬГОТЫ и ГАРАНТИИ HEROES.TATAR 117

- ВОЗМОЖНОСТЬ БЫСТРОГО ПРИОБРЕТЕНИЯ ЖИЛЬЯ ЗА СЧЁТ МИНОБОРОНЫ РОССИИ ЧЕРЕЗ НАКОПИТЕЛЬНО-ИПОТЕЧНУЮ СИСТЕМУ
- СЛУЖЕБНОЕ ЖИЛЬЁ ИЛИ КОМПЕНСАЦИЯ ЗА НАЁМ ЖИЛЬЯ
- БЕСПЛАТНОЕ ОБСЛЕДОВАНИЕ, ЛЕЧЕНИЕ И РЕАБИЛИТАЦИЯ В ВОЕННО-МЕДИЦИНСКИХ УЧРЕЖДЕНИЯХ
- СТРАХОВАНИЕ ЖИЗНИ И ЗДОРОВЬЯ ЗА СЧЁТ ФЕДЕРАЛЬНОГО БЮДЖЕТА
- ПРАВО НА ЛЬГОТНУЮ ПЕНСИЮ ПОСЛЕ 20 ЛЕТ СЛУЖБЫ
- СТАТУС ВЕТЕРАНА БОЕВЫХ ДЕЙСТВИЙ И СООТВЕТСТВУЮЩИЕ ЛЬГОТЫ
- КРЕДИТНЫЕ И НАЛОГОВЫЕ КАНИКУЛЫ
- БЮДЖЕТНЫЕ МЕСТА ДЛЯ ОБУЧЕНИЯ ДЕТЕЙ В ВУЗАХ
- БЕСПЛАТНЫЙ ОТДЫХ ДЛЯ ДЕТЕЙ В ЛЕТНИХ ОЗДОРОВИТЕЛЬНЫХ ЛАГЕРЯХ
- ЕДИНЫЕ ДОПОЛНИТЕЛЬНЫЕ ВЫПЛАТЫ, ЛЬГОТЫ И ГАРАНТИИ СУБЪЕКТОВ РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ ДЛЯ ВОЕННОСЛУЖАЩИХ ПО КОНТРАКТУ

podpiska.pochta.ru

«Әлмәт таңнары»
№37 (13564)
**22 сентябрь,** 2023 ел

Яңалыкларны **almet-rt.ru** сайтында һәм социаль челтәрдәге төркемнәребездә укыгыз

# Яңа автобуслар йөри башлады

## Җәмәгать транспорты йөрешенә кагылышлы сораулар көнүзәк мәсьәләләрнең берсе булып кала бирә

Ничек яшисең, авыл?

Резеда **Исмәгыйлева**

**Укучыларның һәм студентларның җәйге яллары тәмамланганнан соң, автобус һәм троллейбусларга ихтыяҗ икеләтә генә түгел, өчләтә арта.**

Шәһәрдә яшәүчеләрдән тыш авыл кешеләренең дә транспорт белән тәэмин ителешенә кагылышлы сораулар моңарчы гел ачык кала бирде. Шушы көннәрдә, ниһаять, Татарстан Республикасы Рәисенең ярдәме белән районга өр-яңа алты автобус кайтуы турындагы хәбәр авыл кешеләренең йөрәгенә май булып ятты. Матур, иркен, һәрберсе 73 кешене сыйдыра алырлык әлеге «Нефазлар»лар Рус Акташы, Мәмәт, Урсалбаш, Суркин һәм Кәләй авылларына йөри башладылар инде. Әлбәттә, әлеге транспорт чараларын кайтарту бер хәл, аларны карап, кирәк чагында төзәтеп торырга, ягулык белән тәэмин итәргә, шоферларга хезмәт хакы да түләргә кирәк бит әле. Шуңа күрә дә автобуслар «АПОПАТ» җәмгыяте карамагына тапшырылган булып чыкты. Нәрсә генә дисәләр дә, әлеге җәмгыять бүгенге көндә шәһәр яңы маршрутларында биш йөз меңләп халыкны транспорт белән тәэмин итә бит. Предприятие җитәкчелеге дә тарифларны арттыру ягында түгел, киресенчә, шушы күләмдә саклап калуның мөмкинлекләрен эзләүгә өстенлек бирүе турында белдерде.



Яңа автобус ачкычларын район башлыгы Тимур Нагуманов үзе тапшырды. / ФОТО: ӘМР БАШЛЫГЫНЫҢ МАТБУГАТ ХЕЗМӘТЕ.

**Алга таба районда яшәүчеләрне транспорт белән тәэмин итү өчен тагын 7 ГАЗель кайтачагы да билгеле булды. Болары инде Новоникольск, Бишмунча, Миңлебай, Васильевка, Колшәрип, Кузайкино һәм Бута халкына хезмәт күрсәтәчәк.**

Яңа маршрутларның йөреше һәм уңайлылыгы турында Рус Акташы, Мәмәт, Урсалбаш, Суркин һәм Кәләй авылларында яшәүчеләрнең фикерләрен дә бик ишетәсе килгәнлектән, әлеге торак пунктларда яшәүчеләр арасында сораштыру уздырып алдык.

**Мәмәт авыл җирлеге башлыгы вазифаларын башкаручы Артур Владимиров:**

*- Автобус бик кулай. Мәмәтлеләр өчен генә түгел, Чупай, Кичүчат торак пунктларында яшәүчеләр дә әлеге транспортның рәхәтен күрә - автобус каладан килгәндә шушы авылларга да кагылып чыга. Иртәнге якта авыл халкы автобуска утырып эшкә бара, кичке якта эштән кайта. Кичке автобус Әлмәттән 17.30 сәгатьтә чыга, бик уңайлы. Әлмәттән Мәмәткә автобус бәясе дә кыйбат түгел - 69 сум.*

Суркинлылар транспорт йөрешеннән нигездә канәгать калсалар да, автобус тукталышын көйләүгә кагылышлы гозерләре бар икәнлеге билгеле булды.

*- Шәһәрдән шактый ерак яшибез. Автобус суркинлылар өчен бик кирәк. Авылга ул график буенча дүрт тапкыр килеп китә, моның өчен зур рәхмәт. Билет бәясе дә кулай - 80 сум гына. Иң соңгы рейс автобусы Суркинга 18.15 сәгатьтә килеп туктый. Бүгенге көндә ул авылга кадәр төшә, борыла торган урыны да бар. Тик бу хәзер генә шулай булачак, диделәр. Сентябрь аеннан соң авыл халкына автобуска утыру өчен кабаттан авылдан ерак булган урынга - тау башына кадәр җәяү менәргә туры киләчәк. Автобуста күпчелек өлкән яшьтәгеләр, пенсионерлар йөри бит, бик кызганабыз инде аларны. Юл биек, транспорт хәрәкәте өчен куркыныч, дип аклана пассажир ташучылар. Бу мәсьәлә турында кайсы гына җитәкчегә, кайсы гына оешмага язмадык, транспортчылардан да юлны нормаларга туры китерүне үтендек - әлегә хәл ителгәне юк,* - ди бертавыштан Суркин авылы халкы.

**Суркинлыларның үтенечен җитәкчеләр бәлки быел ишетерләр һәм юлны көзге пычрак, иң соңгы чиктә кышкы суыклар башланганчы тиешенчә төзекләндерерләр дип ышанып каласы килә.**

Рус Акташы, Урсалбаш һәм Кәләй торак пунктларында яшәүчеләр дә яңа автобуслардан, маршрут графигыннан бик канәгать булып чыктылар.

# Ышандыргач, эшләргә кирәк

Юллар, юллар...

Резеда **Исмәгыйлева**

**Автобуслар автобуслар белән, ә менә шул транспорт чаралары уңай һәм тотрыклы йөрсен өчен юлларның да төзек булуы кирәк.**

Күпме генә төзекләндерсәләр дә, шәһәр эчендә дә, авыл җирлекләрендә дә ватыкҗимерек юллар байтак әле. Шуларның берсе - Кәләй станциясенә бара торганы. Яңа автобус бу юлдан йөргәндә шөрепләрен коеп бетермәсә ярый инде, дип кайгыра башлаган икән халык. Бу турыда газета редакциясенә тимер юл станциясенә барып кайтканнар да, шул тирәдә яшәүчеләр дә берничә мәртәбә шалтыратып хәбәр иттеләр. Чыннан да, бу юл ник ремонт күрми икән соң? Әлеге уңайдан без Урман Кәләе авыл җирлегенә шалтыраттык. Анда бу юлның региональ юл булуы турында, ә ремонтны «Татнефтедор» үткәрергә тиешлеге турында әйттеләр. «Татнефтедор» җәмгыяте үз чиратында әлеге юл участогының шушындый хәлдә булуы «Алексеевск-Әлмәт» юл участогында барган төзелешкә бәйле икәнлеген әйтте.

*- Әйе, без подрядчылар, без чыннан да ремонтларга тиеш бу юлны. Тик бирегә авыр техника уза, юл җимерелә. Әлегә төзелеш тәмамланмыйча бу юл төзекләндерелмәячәк. Аны хәзер төзекләндерү гомумән мөмкин түгел, авыр машиналар аны барыбер ватып кына бетерәчәк. Бик начар хәлгә килгәч, анда грейдерлар җибәреп, тигезлибез тигезләвен. Юлны төзекләндерү 2024 елда булыр дип планга кертелгән, төгәл вакыты билгесез. Тимер юл станциясенә Чаллы юлы аша керә торган участок төзек,* - дип җавап бирде участок начальнигы Рафис Әхмәтшин.

Урсалы халкы да зарлана юллардан. Бу микрорайондагы кайбер урамнарда юллар шулай ук бик авыр хәлдә, урамнарны яктырту буенча да эшләнәсе эшләр байтак. Күп балалылар яши торган районда, төгәлрәк әйткәндә, Кырлай урамындагы юлны грейдер белән булса да тигезләп чыгуны сорый кешеләр. Халык гозеренә колак салырга вакыт җиткәндер, мөгаен. Җитәкчеләр халык мөрәҗәгатьләрен теркәгәннән соң, аларның үтәлешен дә тикшереп торсалар, әлбәттә, мондый күңелсезлекләр булмас иде. Эшләрлек булмагач, ышандырмаска, ышандыргач, эшләргә кирәк.



«Мондый юлда машинаның шөребе генә түгел, күчәре белән тәгәрмәче дә төшеп калырга мөмкин», - дип зарлана кәләйлеләр.
/ ФОТО: СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРДӘН.

podpiska.pochta.ru

# Игелекле эш бездән кабат бердәмлек таләп итә

## «Ассоль» кафесы каршында һәм «Мегацентр»ның 10 нчы павильонында оешкан штабларда бүген дә эш кайный

Үзебезнекеләрне ташламыйбыз

Резеда **Исмәгыйлева**

**Волонтёрларның күбесе өлкән яшьтәгеләр, пенсионерлар, махсус хәрби операциядә катнашучыларның хатыннары, әниләре, туганнары.**

Өлешчә мобилизация игълан ителгәннән бирле илебез иминлеген сакларга киткән якташларыбызга гуманитар ярдәм оештырып җибәрүчеләр эшләрен бик актив рәвештә алып баралар. Берәүләр маскировка челтәрләре үрә, икенчеләре «Леший» костюмын тегәр өчен материалдан хәзерләмәләр ясый. Студентлар да килгәләп йөри икән. Шулай да җәйге-көзге чорда маскировка челтәрләре үрергә килүчеләрнең саны кимегән. Бүген инде барлыгы 15 кеше генә калган. Бу турыда безгә Рәмия Галимова хәбәр итте.

*- Әлбәттә, әлегә халык бакча эшләре белән мәшгуль булды. Күбесе отпускыда иделәр. Бәлки арыганнардыр да инде. Без әлмәтлеләрнең кабаттан, элеккеге кебек үк, бердәм булып, безгә кушылуларын теләр идек. Үзләре килә алмаганнар акчалата да ярдәм итә алалар. Безнең штабның ишекләре һәркем өчен ачык. Авыл җирлекләре дә баштарак бик актив эшләделәр, челтәрләрен үреп, безгә китерәләр иде, хәзер күренмиләр. 322 нче маскировка челтәрен үрергә керештек менә. Кичә генә госпитальләргә медикаментлар, подгузниклар, урын-җир әйберләре, инвалид колясколары туплап Зәй каласына озаттык. Төп база шунда. Анда гуманитар йөк формалаштырыла һәм фронт яны госпитальләренә озатыла. Госпитальләргә бар нәрсә дә кирәк - калактан алып савыт-сабага һәм чәйнеккә кадәр. Сугышчыларыбыз белән элемтә тотабыз, нәрсә кирәк булуын алар безгә үзләре хәбәр итеп торалар. Сөйләшү барышында солдат егетләребез азык-төлеккә, кием-салымга ихтыяҗ кимегәнен, ә менә маскировка челтәрләренең, «Леший», снайперлар һәм разведчиклар өчен «Кикимора» костюмнарының, тактик носилкаларның аерыча соралган булганын хәбәр иттеләр.*




**Элек челтәрләрне чүпрәк-чапрак, тукымалар кулланып эшләгән булсак, бүген инде без спанбонд материалын заказ белән кайтартабыз. Алар төрле төстә була, ниндиен сорыйбыз - шундыен китерәләр. Бер бобина 5 челтәргә җитә, бәясе ун мең сумлап тора. Аны әле кискәләргә кирәк.**

*Элек кул белән кисеп утыра идек, хәзер, шәһәр паркында эшләүче слесарьлар станок ясап биргәннән соң, эшебез күпкә җайлы. Кабатлап әйтәсем килә инде, ничек тә булса эшебезне активлаштырырга иде, штабка килеп үрергә, тегәргә ярдәм итә алмаганнар акчалата ярдәм итә ала. Финанс ярдәме күрсәтүчеләрнең акчаларына тепловизорлар, генераторлар, балта, чүкеч, төзелеш материаллары сатып алып җибәрә торабыз. Моннан тыш Константин Тимиров командасы ясый торган коры ашлар өчен яшелчәләрне дә штабка китерәләр. Кышкы чорда без йөн җепләр сатып алып, солдатларга оекбашлар бәйләргә теләге булганнарга таратып чыккан идек. Салкыннар башланыр алдыннан әлеге эшне кабаттан дәвам итәргә уйлыйбыз. Социаль челтәрләр аша әлмәтлеләргә бу турыда алдан җиткерәчәкбез. Хәрби госпитальләргә одеялларны, мендәрләрне шул рәвешле туплап Зәйгә озаткан идек инде. Аннан һәр атна саен бер машина махсус хәрби операция зонасына барып, гуманитар йөкне тапшырып кайта. Аллага шөкер, әйберләребез егетләребезгә барып җитә, СВО зонасыннан хәбәрләр даими килеп тора,* - диде волонтёр ханым.

**Әйе, әлеге операция озакка сузылды. Баштарак азарт белән тотынган «ярдәм» дә сүлпәнләнгән. Нинди генә булмасын, эш эш инде. Һәркайсыбыз андагы егетләр урынына үз улыбызны, иребезне, туганыбызны куеп карыйк. Безнең бит инде җаныбызга мүк үсмәгән.**

## Зайцев белән Юдашкин булу кирәкми



Оста

Резеда **Исмәгыйлева**

**Лидия Егорова, «Леший» һәм «Кикимора» маскировка костюмнарын тегүче:**

*- Мине штабта яратып «бабуля Лида» дип кенә йөртәләр инде хәзер* (көлә). *«Алнас»та эшләдем, шуннан пенсиягә чыктым. Гыйнвар аеннан бирле шушы маскировка костюмнарын тегү белән шөгыльләнәм. Штабка килеп тә тегәм, өйдә дә шулар белән утырам. Тегү машинасы тынып тормый. Интернеттан төрле фасоннарны эзлим, аларны тегү техникасын үзләштерәм. Костюмны аерым да, бергә дә киярлек итеп ясыйм. Эльмира дигән волонтёрыбыз материаллар белән бик нык ярдәм итә, размерлар буенча кисеп тә бирә, ә мин өйдә аларны буйыйм. Ярдәмчеләрем дә бар. Егетләребез генә исән булсын инде. Үземнең улым да шул махсус хәрби операция зонасында бит. Штурм төркемендә хезмәт итә, хәрби бүләкләре дә байтак. Әле менә яралануы турында хәбәр килеп ирешә, бераз кайгырып та алдым. Берүк исән-имин генә була күрсен инде. Үзем тегәм, үзем шул солдатларыбызга дога кылам, шуның белән үземне-үзем тынычландырам. Бар да яхшы булыр дип уйлыйм.*

**Аллаһының «амин» дигәненә туры килсен берүк. Фәндә дә бит «уйлар материальләшә» диләр. Чыннан да, маскировка костюмнары тегү өчен Зайцев яки Юдашкин булырга кирәкми. Теләк кирәк. Тегү машиналарыгыз тутыккан булсалар да, күңелләрегез тутыкмагандыр әле, җәмәгать.**

«Әлмәт таңнары»
№37 (13564)
**22 сентябрь,** 2023 ел

Яңалыкларны **almet-rt.ru**
сайтында һәм социаль челтәрдәге
төркемнәребездә укыгыз

# Һаман былтыргы «А», яки Яңа Кәшер мәктәбе шул килеш

Мәктәп еллары гомернең иң гүзәл чагы диләр. Ягымлы һәм гадел укытучылар, сыйныфташлар, күңелле дәресләр... Мәктәп тә төзек һәм матур булса, тагын да гүзәлрәк булыр иде. Тик...



Хат эзеннән

**Әйе, районда үзенең уңышлары белән дан тоткан Яңа Кәшер авылы мәктәбенең бүген шул хәлдә булуы бик аяныч.**

*Хәерле көннәр сезгә!*

*Р. Шаһиевның «Авыл балалары дигәч тә...» дигән мәкаләсен укыгач, мәктәпләре аяныч хәлдәге авыл балалары өчен күңелдә әрнү хисе уянды.*

*Яңа Кәшер авылы мәктәбе 2005 елдан уянып килүче вулкан өстендә яшәгән кебек яши. Бинаның өчтән бер өлеше сүтелгән, төп өлешенең стеналарында ярыклар пәйда булган. Гомумән, баласын укырга җибәргән ата-ананың кичерешләрен әйтеп аңлату мөмкин түгел. Шул ук вакытта район мәгариф идарәсе җитәкчесе үзенең чыгышында бу мәктәпнең авыр хәлдә икәнен беркайчан да тасвирламый; бу мәктәпне идарә җитәкчесе генә түгел, район җитәкчелеге дә күрмәмешкә салыша. Мәктәп ярымҗимерек, тәрәзәләрдән җил-яңгыр үтә, кышкы суыкларда балалар бияләй киеп язалар. Һәм бу 2023 елда! Авыл нефть скважиналары эчендә утыра, ата-аналар нефтьчеләр. Район җитәкчелегенә кирәгебез булмагач, бәлки нефтьчеләр безнең авыл балаларын кайгыртырлар?*

**К. Мөхәммәтшина, Яңа Кәшер авылы**

Ничә еллар дәвамында «йөк» урыныннан кузгалмый. Инде кәшерлеләр мәктәп ишелә дип чаң суга башлаганда исән-сау булган мәктәпләр берничә тапкыр ремонт үткәрделәр. Яңа Кәшер урта мәктәбе исә ничә еллар буена республика планына да, федераль ремонт планына да керми. Сәбәбе нәрсәдә соң? Безнең район җитәкчелеге сорый белмиме? Алай дисәң, райондагы башка мәктәпләр һәрвакыт игътибар үзәгендә. Юк, сүз шәһәрнекеләр турында бармый. Әйтик, Иске Михайловка мәктәбенә әле узган ел гына ремонт ясалды. Әйтүләренә караганда, ата-аналар да, мәктәп, авыл җитәкчелеге дә кайларга гына хат язып карамаганнар. Димәк, әлеге мәктәпкә ремонт ясалмасын өчен кемдер бик каты «тырыша» дими чара юк. «Үз сүземне сүз иттем, барыбер карават астыннан чыкмадым», дигән ир кебек бу. Әгәр дә теләсәләр, шушы еллар эчендә ремонт түгел, ике-өч мәктәп салырга мөмкин булыр иде.

Әлеге хатка ачыклык кертүне сорап мәгариф идарәсенең төзелеш-ремонт эшләренә җаваплы хезмәткәре Алсу Герасимовага мөрәҗәгать иттек. Ул капиталь ремонт өчен бөтен сметаларның, документларның эшләп тапшырылганын хәбәр итте һәм бу мәсьәлә буенча төгәл җавап алу өчен Әлмәт муниципаль районы башкарма комитетының төзелеш, элемтә, транспорт һәм юллар идарәсе начальнигы Илшат Насыйбуллинга мөрәҗәгать итәргә кушты. Тик идарә башлыгы әлеге мәсьәлә буенча җавап бирүдән баш тартты. Мәгариф идарәсе башлыгы Ирина Павловская да соңрак җавап бирермен дигән җөмлә белән чикләнде.

**Бәлки Мәгариф министрлыгындагы белгечләр җавап бирә алыр дигән өмет белән, төзелеш һәм капиталь ремонт эшләрен контрольдә тотучы бүлек белән элемтәгә чыктык. Алар бу эшләр муниципалитет карамагында булуын, һәм узган ел гына республика һәм федераль план кысаларында Әлмәт шәһәре һәм районында 14 мәктәпкә ремонт ясалганын хәбәр иттеләр.**

Сүз дә юк, безнең нефтьчеләр бик күп күркәм, игелекле гамәлләр кылып торалар: төзекләндерәләр, яңарталар, талантлы балаларны кайгырталар, өлкәннәргә булышалар. Ә бит аларның төп эше нефть чыгару.

Бүген 132 бала белем алган Яңа Кәшер мәктәбе бер кысага да керми, күрәсең. «Булмый инде булмагач, Актанышта тумагач, Сабаларда тумагач», дип белми җырламый инде Илсөя. Алай дисәң...

Нәтиҗә ясап шуны гына әйтәсе кала, җәмәгать, кулыгызда власть таягы белән мөһер, дәрәҗәгез булганда үзегезнең кендек каны тамган авылга, сине зур кәнәфидә утыра торган җитәкче булырлык итеп белем биреп чыгарган мәктәбегезгә ярдәм итеп, карап, төзекләндереп торыгыз. Аннан соң булуы бар. Власть та, дәрәҗә дә вакытлы гына ул.

**Рәфкать Шаһиев әзерләде**

## «Сүз дә, түземлек тә бетеп килә...»

Фикерләр

**Авыл мәктәбенең мондый хәлдә булуы ата-аналарны да борчуга сала. Фикерләрне беләсе килеп, мөрәҗәгать иткәч, кемнәрдер баш тартты, кайберләре исемнәрен күрсәтмәүләрен үтенделәр, чөнки беркемгә дә интервью бирмәскә, журналистлар белән аралашмаска кушылган. Ләкин шуңа да карамастан аларның үз сүзләре бар.**

**Рузана:**
*- Инде кайларга гына мөрәҗәгать итеп бетермәдек. Мәскәүгә В. Путинга да, үзебезнең Рәисебез Р. Миңнехановка да, якташыбыз дип Ф. Мөхәммәтшинга да язып карадык. Бөтен сүз финанска барып терәлә бугай. Балам 2 нче сыйныфта укый, икенчесенә әле биш кенә яшь. Каядыр башка мәктәпкә йөртәсе дә килми, мөмкинчелегебез дә юк. Ә безнең мәктәптә бик көчле укытучылар, төпле белем бирәләр. Аннан каядыр чыгарып җибәрсәң дә, Алла сакласын, юлда ниләр булмас. Монда мәктәпкә киткәндә дә куркып торабыз. Кырыйдан караганда бик куркыныч инде. Әле күптән түгел генә дә районнан килеп карап киттеләр, безнең белән очраштылар. Нигезләре яхшы, шулай да ныгытырга кирәк, кайбер стеналарын алыштырырга диләр. Өметләнәбез инде. Бәлки икенче балабыз төзек мәктәпкә барыр.*

**Айгөл Хөснетдинова:**
*- Мин бу авыл килене. Ирем укыганда ук шул җимерек хәлдә булган инде. Хәзер бер балабыз тәмамлап чыкты, икенчесе укый. Ни өчен шушы хәлдә - һич җавап таба торган түгел. Очрашуга, җыелышка килгән бер генә кеше дә «юк» дип каршы килми. Һәркайсы «булыр» дип вәгъдә бирә. Баштарак төрле программаларга да керде дип карадылар инде. Ничек кергән, шулай чыгып та киткән, күрәсең. Әллә нинди кечкенә генә авылларга да мәктәпләр салып бетерделәр.*

***Ничек дип әйтергә дә, нәрсә уйларга да белгән юк инде. Әллә ремонтка дигән акчалар күптән тотылып беттеме икән дигән уйлар да килә. Сүз дә юк, бүген заман таләбенә туры килә торган мәктәп төзү өчен миллионнар гына түгел, миллиардлар кирәктер. Ләкин бит ремонт ясарга мөмкиндер. Тирә-як авыллардан оят. Ә укыту бик яхшы. Мәктәп коллективы төпле, ныклы белем бирә.***

**Ринат Гарипов:**
*- Монда сүз юк инде. Сүз дә бетә, түземлек тә бетеп килә. Алла сакласын, андый-мондый фаҗига генә була күрмәсен. Ул бит гел булмый, бер генә була. Ул «обещалкин»нарның үзләренең балаларын шушы мәктәпкә җыеп китереп утыртасы иде. Безнең мәктәптәге һәр укытучыга медаль бирерлек. Балалар шәһәрдәге кебек репетиторга йөреп ЕГЭ тапшырмый, үзебезнекеләр укыта.*

***Ә мәктәпне ремонтлатырга дигән акчаларны эзләтергә кирәк. Ул бит кайдадыр булырга тиеш. Әлмәттә тегесе урлаган, монысы урлаган дип берәм-берәм чүпли торалар. Монда да шул кирәк. Шунсыз мәктәпкә ремонт күрмәбез кебек.***

pdfiska.pochta.ru

# Бердәмлек һәм теләктәшлек бәйрәме

## Татарстан Республикасы Профсоюзлар көне киң колач белән, шаулап-гөрләп билгеләп үтелде

**Ел саен бу бәйрәм Татнефть Профсоюз канат астында, компания эшчәнлек алып барган төрле калаларда үткәрелә. Быел аны Лениногорскида үткәрделәр.**



Бәйрәм кунаклары Шөгер авылындагы Нефть музеенда булдылар. / ФОТО: ТАТНЕФТЬ ПРОФСОЮЗ.



Тырыш хезмәткәрләр Татнефть Профсоюз җитәкчелеге кулыннан лаеклы бүләкләр алды. / ФОТО: ТАТНЕФТЬ ПРОФСОЮЗ.

Бәйрәм Шөгердә «Татнефть» өчен гаять истәлекле урыннардан башланды. Бәйрәм кунаклары җир катламнарына тәүге юл ачкан - ерак 1943 елда республиканың зур нефте тарихына башлангыч биргән скважина янында булдылар. Биредә мастер Гариф Хәмидуллин бригадасы тәүлегенә 20 тонна дебит белән кара алтын чыгаруга ирешкән. Нефтьле катламның зурлыгы һәм көчкуәте сәнәгый әһәмияткә ия булган нефть ятмасының ачылуына дәлил булып тора.

*- Татарстан нефте юктан гына барлыкка килмәгән. Бу - нефтьчеләр, бораулаучылар, геофизиклар, геологлар һәм нефть эшкәртүчеләрнең дистәдән артык буынының тырыш хезмәте нәтиҗәсе. Нефть чыгарыла башлаганнан бирле профсоюз оешмасы күп кенә мәсьәләләр белән шөгыльләнә. Бүген дә бурычлар үзгәрмәде. Без профсоюз әгъзаларына хезмәт законнары кысаларында яраткан эшләре белән лаеклы шөгыльләнә алсыннар өчен шартлар тудыруны бүген дә дәвам итәбез,* - дип ассызыклады Татнефть Профсоюз МПО рәисе урынбасары Рифдар Хамадьяров.

*- Биредә нефтьнең беренче тонналары барлыкка килгән, Социалистик Хезмәт Геройлары, Советлар Союзы Геройлары туган һәм үскән. Без үз җирлегебездә «Татнефть» компаниясе профсоюз хәрәкәтенең тууы, беренче коллектив килешү, яшьләр һәм ветераннар оешмалары барлыкка килүе белән нык горурланабыз. Ата-бабаларыбыз тарафыннан нигез салынган традицияләрне хөрмәт итүне дәвам итәбез һәм хезмәт кешесе файдасына мөмкин булганның барысын да эшлибез,* - дип билгеләп үтте «Татнефть» компаниясе ОППОсының Лениногорск территориаль башлангыч профсоюз оешмасы (ТППО) профком рәисе Юлия Новичкова.

**Шөгердәге Нефть музеенда кунаклар төбәкнең борынгы нефть тарихын күрделәр. Бу урын туры мәгънәсендә үткән заман рухы белән сугарылган - Шандыр тавы шахтасыннан салкынлык исә, штольняда тавышлар, ә тимерче алачыгында эш коралы белән чүкечкә шакылдаган тавыш ишетелә. Иң кызыксынучаннарга үзләрен бу һөнәрдә сынап карау бәхете дә тәтеде.**

*- Мин Лениногорскида тудым. Бу урыннарда без һәрвакыт җиләк җыя идек. Ул вакытта завод эшләми иде инде, мондый җиһазландырылган тарихи үзәк тә юк иде әле. Менә бүген, 25 елдан соң, мин монда беренче тапкыр килдем. Музей миндә бик зур тәэсир калдырды, чималның ничек чыгарылуын, ничек ватып, юуларын күрсәттеләр. Якташларыбызның нинди авыр хезмәт белән шөгыльләнгәннәрен күрдек,* - дип уртаклашты «Татнефть» компаниясе ОППОсының Әлмәт ТППОсы әйдәп баручы белгече Венера Ехаева.

Көн Тимәштә 3 нче санлы скважина янындагы һәйкәлгә чәчәкләр салу белән дәвам итте.

*- 1948 елда Тимәш җиреннән нефть фонтаны бәреп чыга. Бүген җир катламнарына тәүге юл яручыларның һәм бүгенге буын нефтьчеләрнең фидакарь хезмәте нәтиҗәсендә компания тарафыннан 3,5 миллиард тоннадан артык нефть чыгарылган, һәм ул республика һәм илебез файдасына хезмәт итә,* - дип игътибарны юнәлтте Татнефть Профсоюз рәисе Гомәр Яруллин.

*- Бүгенге буын традицияләрне, тарихны хөрмәт итә, тармак ветераннарына карата бик ихтирамлы мөнәсәбәттә. Ә профсоюз исә һәрвакыт хезмәткәрләр белән аралашып тора, бу аларга уңайлы шартларда эшләргә, лаеклы хезмәт хакы алырга һәм үз потенциалларын тормышка ашырырга мөмкинлек бирә,* - дип дәвам итте компаниянең яшьләр комитеты рәисе Дмитрий Несмин.

Бу көнне заманында нефть сәнәгате министры, «Татнефть»нең икенче җитәкчесе булган В. Шашин һәйкәленә, Лениногорскида Геройлар Аллеясында һәм Нефтьчеләр аллеясында чәчәкләр салынды.

Бәйрәмнең тантаналы өлеше компаниянең тырыш хезмәткәрләренә хөрмәт күрсәтү белән тәмамланды. Алар «Татнефть» һәм Татнефть Профсоюз җитәкчелеге кулыннан лаеклы бүләкләр алдылар.

*- Профсоюзлар һәрвакыт үз тирәсенә белем буенча да, инновацияләрдә һәм башка мөһим өлкәләрдә дә лидер булганнарны җыйдылар һәм эшне бишьеллыклар планын арттырып үтәү белән ярышырлык дәрәҗәдә итеп оештырдылар,* - дип ассызыклады баш геолог - «Татнефть» компаниясе генераль директоры урынбасары Ринат Әфләтунов.

**Төштән соң ЗАГС бинасы янында төрле активлык зоналары: уен мәйданчыклары, мастер-класслар, сабын куыклары белән шоу һәм башкалар җәелдерелде. «Легкие крылья» урам театры артистлары моңарчы күрелмәгән әкият персонажларына әверелделәр, үзләренең иҗатын һәм елмаюларын өлкәннәр һәм балалар белән уртаклашып, һәркемгә яхшы кәеф бүләк иттеләр.**

Танып-белү белән бәйле эшчәнлектә катнашырга теләүчеләр дә бик күп булды. Балалар популяр көйләр астында биеделәр, уеннар уйнадылар, мастер-классларда сулы буяулар белән рәсем ясарга өйрәнделәр. Аквагрим кулланып рәсем төшерү һәм ялтыравыклардан татуировкалар ясау өчен чират тезелде. Биредә үк ярминкә дә гөрләде. Кыр кухнясында итле карабодай боткасы һәм кайнар чәй белән сыйладылар.

Казаннан, Санкт-Петербургтан килгән популяр артистлар башкаруында танылган җырлар, мәңге онытылмас классика, татар көйләре, заманча яшьләр композицияләре яңгырады.

Лениногорскилылар үзләре өчен татар халык җырларын башкаручы яшь йолдызны, сөйкемле җырчы Сәйдә Мөхәммәтҗанованы ачтылар, «Мәдәни мохит-2023» буенча яхшы таныш булган, татар һәм рус эстрадасы шедеврларын башкарган Рамил Галимҗановны, яңгыравык тавышлы «Ворожея» төркемен алкышладылар. «Казан» бию ансамбленең дәртле ритмнары астында биеделәр. MIB (ЭмАйБи) һәм «Ямьле» вокаль триоларын, Эльмира Җәлилова, Радик Шәрипҗанов, Лениногорскиның яшь, талантлы башкаручысы Данил Солтановны җылы каршы алдылар. Халыкка киң танылган татар һәм рус композицияләрен бүләк иткән «ВИА хит» кавер-төркеме дә беркемне дә битараф калдырмады. «Холодно-Горячо», «Зацепила» һәм башка хитлары белән чыгыш ясаган Chris Yank (Крис Янк) программасы да йөрәкләргә үтеп керерлек булды.

Профсоюзлар көне гаять күңелле үтте, кешеләргә озакка җитәрлек энергия, көч-дәрт бүләк итте.

**Анастасия Петрова,**
**Айсылу Габбасова**

«Әлмәт таңнары»
№37 (13564)
**22 сентябрь,** 2023 ел

Яңалыкларны **almet-rt.ru**
сайтында һәм социаль челтәрләрдәге
төр[...]ребездә укыгыз



# Авыл «чика»сы кайда да сынатмый

Заман белән бергә халыкның яшәү рәвеше, кәсеп-һөнәрләре дә үзгәрә. Блогер булуны бүгенге көн кәсебе дисәк, ялгыш булмас

Проект

Резеда **Исмәгыйлева**

**Газетабыз битләрендә авыллар һәм шушы торак пунктларда яшәүче халыкның тормышы-көнкүрешенә, истәлекле вакыйгаларга, шәхесләргә кагылышлы сәхифәләргә күбрәк урын бирергә тырышабыз.**




Авылда туып-үскән, шунда төпләнеп калган кешеләр - хөрмәткә иң лаек кешеләр. Алар белән очрашып, гади генә аралашып утыруы гына да үзе бер рәхәт. Һәм бу бернинди дә пафос түгел. Кечеме, зурмы ул торак пункт, аның төп байлыгы кешеләр бит. Авыл тормышы белән янып-көеп йөрүчеләргә мең рәхмәт булса, үзләренә кагылышлы вакыйгаларны гади һәм шул ук вакытта бик үтемле итеп яктыртып баручы язучыларга, шагыйрьләргә һәм, әлбәттә, заманча блогерларга да «афәрин!» дими ни дисең. Бу турыда редакциябездә кунакка килгән Әлмәт блогеры Альбина Вәлиева белән дә сөйләшеп, фикер алышып утырырга туры килде. Тормышындагы һәр мизгелне социаль челтәрләр аша матур итеп җиткерә белүче «деревенская чика» безгә икенче тапкыр кунакка килүендә үзенең ни өчен авылда яшисе килүе, ничек итеп читтән төзүчеләрне ялламыйча, үз кулларың белән йорт җиткерергә мөмкин булуы турында сөйләде, блогерлык эшчәнлегендәге алдагы планнары белән уртаклашты.

*- Авыл кызы булганлыктан, минем берәр авыл җирендә төпләнеп, йорт салып керү теләгем балачактан ук бар иде. Менә, ниһаять, әлеге хыялым чынга ашты. Колшәрип авылы аеруча күңелемә хуш килде инде. Бу торак пункт калага якын урнашуы, төзек һәм матур булуы белән җәлеп итте. Алла бирсә, октябрь аенда йортка күчеп, өй туйлары үткәрергә чамалыйбыз. Алданрак та күчкән булыр идек - газны сентябрь азакларында гына кабызабыз, диделәр. Җир астыннан газны ике сәгатьтә керттеләр, ялгап, эретеп ябыштыру эшләре белән бергә булган вакыт бу, счетчиклар да куелды, ә менә документлаштыру эше ай-яй озак булды инде. Гомумән, йорт рәсмиләштерү берәр айга кадәр сузылды. Тегесе кирәк, бусы кирәк, кәгазь волокитасы инде. Коммуникацияләр ясау белән проблема булмады. Суга килгәндә, авылда үзәкләштерелгән су системасы да бар, шулай да скважинаны үзебез борауладык һәм дөрес эшләдек дип уйлыйм. Гомумән, авыл җирлегендә җәен су проблемасы гел килеп чыга бит инде. Без моны алдан ук чамаладык һәм суны үзебез казып кертергә булдык. Авылларда элек-электән үк һәрбер ихатада кое булган. Бу - янгынга каршы тору чарасы да бит әле. Утлар да Колшәриптә «гөлт» итеп тора, ә менә яңа урамнарда юллар юк инде. Хатлар да язып карадык, «үз көчегез белән салыгыз» диделәр. Күпләр шулай эшли икән. Яши башлагач, алга таба теплица урнаштырып, җиләк-җимеш һәм башка яшелчәләр үстерүне планга кертеп куйдым инде. Алга таба кош-корты да булыр бәлки,* - диде Альбина.



Сөйләшә торгач, блогерның үзенең эшчәнлеген сатучылык өлкәсендә дә үстерергә уйлап торуын белдек.

*- Хәзер бит инде күпләр маркетплейска чыга, шул уңайдан мин дә тәвәккәлләргә булдым әле. Ходай кушса, октябрь айларында билгеле бер сату мәйданына чыгам, нинди товар белән чыгасымны инде уйладым. Беләсезме, быелга нинди планнар, максатлар куйган идем - барысы да чынга ашты бит. Йортлы да булдык, кызым белән диңгездә ял да итеп кайттык, топ-блогерлар белән дә якыннан таныштым. Чирмешән районы Иске Кади авылында кабат икенче тур оештырып, блогерларга искитмәле күңелле очрашу, аралашу мизгелләре бүләк иткән өчен Равил Закировка зур рәхмәт. Блогерлар белән бергәләшеп җырлый-җырлый көтү кудык, сыер саудык, тирес түктек, сарай чистарттык - бар авыл эшен башкардык инде. Сөт тапшырырга баргач, аны нинди арзан бәягә сатып алуларына гына шаклар каттык. Авыл кешесенең күпме хезмәте кергән бит аңа югыйсә. Менә шулай, эшләдек тә, ял да иттек.*

***Ике йөзләп авыл кешесенә концерт куйдык, саф һавада ухалар пешереп, балыклар ыслап, җырлар җырлап утырдык. Көннәребез бик кызык, бик тиз үтте. Хәзер инде үзара аралашып торабыз. Мондый проектлар булса, алда да катнашачакмын.***

*Блогер буларак, алда үземнең образны камилләштерү өстендә дә эшләргә кирәк әле. Кешеләр мине күрә, таный башладылар хәзер, шуның өчен Ходайга мең рәхмәт,* - дип куанычын белдерде Альбина Вәлиева.

**Блогер ханымга уңышлар юллыйбыз һәм аның, яңадан-яңа һөнәрләр үзләштереп, авыл тормышына багышланган сәхифәләрен алга таба да шулай дәвам итүен телибез.**

Язма РФ Цифрлы үсеш, элемтә һәм массакүләм коммуникацияләр министрлыгының финанс ярдәме белән әзерләнде



# Мәмәтлеләрнең бренды

## Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз. Заманында Мәмәт авылында кулына балта-пычкы тотмаган ир-ат булмагандыр

Хәтер

Рәфкать **Шаһиев**

**Рөстәм Закиров башкаруында «Пошалым чаналары» дигән җыр бик күпләргә таныштыр. Аны тыңлаучылар җырларга керерлек чаналарны Казан артында гына ясыйлар икән дип уйласалар, ялгышалар.**

Заманында атаклы балта осталары авылы булган Мәмәт. Бер уйласаң, һәр төбәкнең, һәр авылның ниндидер үз «бренды» бар. Мәмәттә элек-электән чана һәм арба ясаганнар. Дөресен генә әйткәндә, ул чорда чаналарга ихтыяҗ зур булса да, авылларда чаначылар-арбачылар бик аз була. Чөнки әлеге хезмәт шактый авыр, физик көч һәм зур осталык сорый. Тиешле агачын табарга, дөрес итеп, технологиясен белеп, җиренә җиткереп әзерләргә кирәк. Ул һөнәр ияләре сирәк була. Бүген инде авыл җирлекләрендә атлар да юк дәрәҗәсендә, тарих дәреслекләреннән өйрәнгән мамонтлар, динозаврлар кебек. Чана ясаучылар, арба эшләүчеләр дә тарихта калды. Мәмәт авылындагы әлеге кәсепкә караган «тарих битләрен» укытучы Гөлнур Миннегалимова һәм шәхси музейлары белән тирә-якка танылган Ләлә һәм Марат Ситдыйковлар барлап торалар.

Нәбиулла Әгълиуллинның балалары һәм Нажия апа Миннегалимовалардан алган мәгълүматларны Гөлнур ханым безнең белән дә уртаклашты.

*- Мәмәттә алар дистәгә якын булганнар: Вафин Сафа, Вафин Ихсанвәли, Хәсәншин Гали, Нуриәхмәтов Нурулла, Әгълиуллин Газизулла, Әгълиуллин Нәбиулла, Фәрхетдинов Фатих, Мортазин Минразый, Маннанов Гата, Ахунов Зәки.*



Нурулла бабай Нуриәхмәтов үргән чабата. Мәмәт мәктәбенең «Туган якны өйрәнү» музеенда. / ФОТО: ЛӘЛӘ СИТДЫЙКОВА.



Минразый абый Мортазин ясаган чана. Марат Ситдыйковның шәхси музей биләмәсендә саклана. / ФОТО: ЛӘЛӘ СИТДЫЙКОВА.

### Газизулла абый

*- Газизулла абый ат чанасы гына ясамый, ә инде балалар өчен дә чаналар ясый иде. Кайсыларын артлы итеп ясый һәм матур итеп бизәкләр дә төшерә. Шул чорның акчалы кешеләре шундый чаналарга заказ күп бирә торган булганнар. 1953-1954 елларда нефтьчеләр өчен Чупай авылында бараклар төзелгән, кибет, шәһәрдәге кебек зур базар ачылган. Газизулла абый шулай итеп базарга барып балалар чанасы сата башлый. Матур чаналар тирә-юньгә бик тиз тарала,* - дип хатирәләре белән уртаклаша Нажия Миннегалимова.

**Ул шулай ук ат чанасы да ясый. Ә аны «бартер»га, атка алмаштыра (унөч-унбиш чанага бер ат). Шулай итеп чаначылар атлы була. Яшәргә, ашарга, гаилә алып барырга кәсепләре була. Көндез эштә, ә кичен авыр булса да, төшемле эш үзенекен итә. Уңган авылдашлар тирә-якка данлыклы булалар.**

### Нәбиулла бабай

Нәбиулла бабай да тарантаслар, бәби бишекләре ясаган, аның туганы да чана табаннары бөккән. Гомумән, нәселдә бер ир туганы ни дә булса эшләргә өйрәнә икән, аны башка туганнары да күтәреп алганнар.

Әлеге эштә иң четереклесе дә шушы - чана табаны бөгү икән инде.

*- Чана табанына имән кирәк, ул иң нык агачларның берсе,* - дип аңлата оста. - *Табан бөгәргә имәннең дөрес итеп пешүе мөһим. Элек аның сыйфатын белү өчен бабайлар чәйнәп тә караганнар әле. Пешүе җиткән имән җиңел бөгелә. Ә менә пешүе җитмәсәме?! Инде булды, бөгелде генә дисең, дугаланып килгән урыннан «черт» итә дә сынып китә. Шуңа да бу эш чана ясауның иң җаваплы, иң теңкәне корыта торган өлеше,* - диләр Нәбиулла аганың балалары.

Чана ясау элек кулланышта булып, хәзер онытыла барган сүзләрне дә искә төшерә. Әйтик: үрәчә. Бу сүзне өлкәннәр белсә дә, яшьләр ни икәнен дә аңламый.

**Үрәчә - арба яки чананың як-ягында буйга сузылган агач. Анысын юкәдән ясыйлар. Үрәчә белән табанны үзара беркетер өчен имән кигиләр дә кирәк әле. Алары - алтау. Ике үрәчәне карама тоташтыра. Анысы, исеме үк әйтеп тора, карама агачыннан ясала.**

### Минразый абый

*- Әтием балта остасы, алтын куллы кеше иде. Ул матур итеп бизәкләп балалар чанасы, шкафлар, көянтә, ат чаналары ясый иде. Чана табанын бөгү бик зур тырышлык сорый. Артык кыздырсаң, табан ярылып китә, әзрәк җылытсаң, бөгелми. Безгә дә әти янында аңа булышып йөрергә туры килгәләде. Заказ белән ясаган чаналарны бик еш кына Азнакай районы Чалпы авылыннан бер абзый алып китә торган иде. Әмма исемен хәтерләмим. «Октябрьнең 50 еллыгы» исемендәге совхозга да заказ белән бик күп чана ясады. Әтием 1989 елның декабрендә лаеклы ялга чыкты. 2001 елның 17 октябрендә вафат булды.*

*Мәмәт авылына Чупай авылы яклап кайтканда, юл кырыенда тезелешеп усак агачлары үсеп утыра. Шушы юлдан кергәндә һәрвакыт әтием искә төшә. Бу үсентеләрне утыртканда әтием бик актив катнашкан иде,* - дип искә ала кызы Назирә.

**Бабасы Нурулла Нуриәхмәтов турында оныгы Алсу да истәлекләр туплаган:**

*- Ул 1908 елда туа, ишле гаиләдә тәрбияләнә. Балалык чоры әти-әнисенә булышып, җир сөреп, тырмалап, урак урып үтә. Ә үсә төшкәч, балта белән эшләү серләрен үзләштерә һәм авылда бер оста булып җитешә. Ул колхозда йөк ташу өчен үрәчәле чаналарның зурысын һәм кечесен, балалар өчен дә чаналар ясаган. Үз кулы белән ясаган агач әйберләрне Бөгелмә базарында сата торган булган хәтта. Тирә-як авылларда аның турында ишетмәгән, аның чаналарын сорап килмәгән кеше калмаган. Нурулла бабам балта остасы гына түгел, чабатачы да булган. Башкалардан җитезлеге белән аерылып торган. Мәктәбебезнең «Туган якны өйрәнү» музеенда ул ясаган чабаталар әле дә саклана.*

**Әлбәттә, осталар бер чана-арба белән генә чикләнеп калмыйлар. Авыл халкына тормыш-көнкүрештә кирәк булган гөбе (май язу җайланмасы - миксер), киштәләр һәм тәрәзә йөзлекләре дә ясыйлар. Гаиләдәге һәр кеше, бала-чагалар да әтиләренә булышып эш-һөнәргә өйрәнеп үсәләр.**

Алар ясаган җиһазларны Лениногорск, Азнакай, Сарман районнарыннан да сорап киләләр. Шул рәвешле тирә-як районнарны да арба-чана белән тәэмин итеп торалар.

Бүген инде башка заман, башка кәсеп. Ул хакта алдагы саннарыбыздан укырсыз.

Язма РФ Цифрлы үсеш, элемтә һәм массакүләм коммуникацияләр министрлыгының финанс ярдәме белән әзерләнде

«Әлмәт таңнары»
№37 (13564)
**22 сентябрь,** 2023 ел

Яңалыкларны **almet-rt.ru** сайтында һәм социаль челтәрдәге төркемнәребездә укыгыз

## «ЮВТ-24»

**Дүшәмбе, 25 сентябрь**

**00.00** Из архива телекомпании. «Православный календарь» (16+)
**00.15**, 01.15 «И в шутку, и всерьез» (6+)
**01.00** Из архива. «Безнең вакыт» (16+)
**06.00**, 18.15, 23.15 Проект «Татмедиа Джуниор» (16+)
**07.00** ТРның көньяк-көнчыгыш хәбәрләре. Атналык күзәтү (16+)
**11.30** Новости юго-востока РТ. Итоги недели (16+)
**14.30**, 22.00 Городская среда (16+)
**18.00**, 23.00 Без сезгә барабыз (16+)
**19.00** Новости юго-востока Татарстана (16+)

**Сишәмбе, 26 сентябрь**

**00.00**, 07.00, 11.30, 19.00 Новости юго-востока Татарстана (16+)
**01.00**, 06.00 Без сезгә барабыз (16+)
**01.15**, 06.15, 18.15, 23.15 Проект «Татмедиа Джуниор» (16+)
**14.30**, 22.00 Городская среда (16+)
**18.00**, 23.00 Татарстанның көньяк-көнчыгыш хәбәрләре (16+)

**Чәршәмбе, 27 сентябрь**

**00.00**, 07.00, 11.30, 19.00 Новости юго-востока Татарстана (16+)
**01.00**, 06.00, 18.00, 23.00 Татарстанның көньяк-көнчыгыш хәбәрләре (16+)
**01.15**, 06.15, 18.15, 23.15 Проект «Татмедиа Джуниор» (16+)
**14.30**, 22.00 Городская среда (16+)

**Пәнҗешәмбе, 28 сентябрь**

**00.00**, 07.00, 11.30, 19.00 Новости юго-востока Татарстана (16+)
**01.00** Из архива телекомпании. «Православный календарь» (16+)
**01.15** «И в шутку, и всерьез» (6+)
**06.00** Татарстанның көньяк-көнчыгыш хәбәрләре (16+)
**06.15**, 18.15, 23.15 Проект «Татмедиа Джуниор» (16+)
**14.30**, 22.00 Городская среда (16+)
**18.00**, 23.00 Без сезгә барабыз (16+)

**Җомга, 29 сентябрь**

**00.00**, 07.00, 11.30, 19.00 Новости юго-востока Татарстана (16+)
**01.00**, 06.00 Без сезгә барабыз (16+)
**01.15**, 06.15, 18.15, 23.15 Проект «Татмедиа Джуниор» (16+)
**14.30**, 22.00 Городская среда (16+)
**18.00**, 23.00 Татарстанның көньяк-көнчыгыш хәбәрләре (16+)

**Шимбә, 30 сентябрь**

**00.00**, 07.00 Новости юго-востока Татарстана (16+)
**01.00**, 06.00, 18.00, 23.00 Татарстанның көньяк көнчыгыш хәбәрләре (16+)
**01.15**, 06.15, 11.45 Проект «Татмедиа Джуниор» (16+)
**11.30** Без сезгә барабыз (16+)
**14.30**, 22.00 Городская среда (16+)
**19.00** Новости юго-востока Татарстана. Итоги недели (16+)

**Якшәмбе, 1 октябрь**

**00.00**, 07.00 Из архива телекомпании. «Православный календарь» (16+)
**00.15**, 01.15, 23.15 «И в шутку, и всерьез» (6+)
**06.00** Проект «Татмедиа Джуниор» (16+)
**07.00**, 18.00 ТРның көньяк-көнчыгыш хәбәрләре. Атналык күзәтү (16+)
**11.30**, 19.00 Новости юго-востока Татарстана. Итоги недели (16+)
**14.30**, 22.00 Городская среда (16+)

## «ЛУЧ-ӘЛМӘТ»

**Дүшәмбе, 25 сентябрь**

**07.00**, 19.15, 19.35, 21.15, 21.35 Погода (6+)
**07.05** Сладкая жизнь. Кулинарная программа (12+)
**07.25 Д/ф «Спасенные фрески Спасо-Преображенского собора Мирожского монастыря»** (12+)
**08.20, 04.10 Д/ф «Не факт»** (12+)
**08.55** Михаил Шуфутинский. Love Story - Юбилейный концерт в день рождения (16+)
**11.00 Х/ф «Генерал Де Голь»** (16+)
**12.45 Д/ф «Происхождение: пять элементов человеческой цивилизации»** (6+)
**13.30 Х/ф «Каникулы Джой»** (12+)
**15.25, 05.25 Т/с «Акватория»** (16+)
**16.10, 03.20, 06.00 Т/с «Сватьи-2»** (16+)
**17.05, 04.35 Д/ф «Горизонт приключений. Крым»** (12+)
**18.00 Т/с «Фронт»** (12+)
**19.00**, 21.00 Новости (12+)
**19.20**, 21.20 Яңалыклар вакыты (12+)
**19.40** Ваш ЛУЧший вечер (6+)
**21.40 Х/ф «Шугалей-3»** (16+)
**23.25, 00.15 Т/с «Убийства в ...»** (16+)
**01.05 Д/ф «Национальный парк Югыд Ва»** (12+)
**01.45 Х/ф «Двое под одним зонтом»** (12+)

**Сишәмбе, 26 сентябрь**

**07.00**, 12.15, 19.00, 21.00 Новости (12+)
**07.15**, 07.32, 19.15, 19.35, 21.15, 21.35 Погода (6+)
**07.17**, 12.30, 19.20, 21.20 Яңалыклар вакыты (12+)
**07.35, 18.00 Т/с «Фронт»** (12+)
**08.30, 04.10 Д/ф «Не факт»** (12+)
**09.05 Т/с «Убийства в ...»** (16+)
**10.00 Х/ф «Каникулы Джой»** (12+)
**11.40 М/ф «Золотая антилопа»** (0+)
**12.50 Д/ф «Цикл «Битва ставок»** (12+)
**13.35 Х/ф «Вспоминая тебя»** (16+)
**15.25, 05.20 Т/с «Акватория»** (16+)
**16.10, 03.20, 06.00 Т/с «Сватьи-2»** (16+)
**17.05, 04.35 Д/ф «Горизонт приключений. Алтай»** (12+)
**19.40**, 20.25 Ваш ЛУЧший вечер (6+)
**20.00** Время «Татнефти» (12+)
**21.40 Х/ф «Лейтенант Суворов»** (12+)
**23.25 Х/ф «Шугалей-3»** (16+)
**00.55 Д/ф «Происхождение: пять элементов человеческой цивилизации»** (6+)
**01.45 Д/ф «Золото неизвестных вождей. Курские клады»** (12+)
**02.00 Д/ф «Микульчище. Древний центр великой Моравии»** (12+)
**02.10 Д/ф «Свияжск. Музей археологического дерева»** (12+)
**02.25 Д/ф «Археология Таймыра»** (12+)
**02.40 Д/ф «Мангазея. Торговая столица Сибири»** (12+)
**02.55 Д/ф «Селькупы. Хозяева Сибирской тайги»** (12+)

**Чәршәмбе, 27 сентябрь**

**07.00**, 12.15, 19.00, 21.00 Новости (12+)
**07.15**, 07.32, 19.15, 19.35, 21.15, 21.35 Погода (12+)
**07.17**, 12.30, 19.20, 21.20 Яңалыклар вакыты (12+)
**07.35, 18.00 Т/с «Фронт»** (12+)
**08.30, 04.10 Д/ф «Не факт»** (12+)
**09.00 Т/с «Убийства в ...»** (16+)
**09.55 М/ф «Птицы как мы»** (6+)
**11.25 Д/ф «Золото неизвестных вождей. Курские клады»** (12+)
**11.45 Д/ф «Микульчище. Древний центр великой Моравии»** (12+)
**12.00 Д/ф «Свияжск. Музей археологического дерева»** (12+)
**12.45** Время «Татнефти» (повтор) (12+)
**13.20 М/ф «На лесной эстраде»** (0+)
**13.35 Х/ф «Вспоминая тебя»** (16+)
**15.25, 05.20 Т/с «Акватория»** (16+)
**16.10, 03.20, 06.00 Т/с «Сватьи-2»** (16+)
**17.10, 04.30 Д/ф «Горизонт приключений. Алтай»** (12+)
**19.40** Ваш ЛУЧший вечер (6+)
**21.40 Х/ф «Драконы Нью-Йорка»** (16+)
**23.30 Х/ф «Лейтенант Суворов»** (12+)
**00.55 Д/ф «Цикл «Битва ставок»** (12+)
**01.30 Д/ф «Шаманы Таймыра»** (12+)
**02.20 Д/ф «Происхождение: пять элементов человеческой цивилизации»** (6+)

**Пәнҗешәмбе, 28 сентябрь**

**07.00**, 12.15, 19.00, 21.00 Новости (6+)
**07.15**, 07.32, 19.12, 19.35, 21.15, 21.35 Погода (6+)
**07.17**, 12.30, 19.15, 21.20 Яңалыклар вакыты (12+)
**07.35, 18.00 Т/с «Фронт»** (12+)
**08.30, 04.10 Д/ф «Не факт»** (12+)
**09.05** Ретроспективный показ ТК «Луч». Сельская жизнь. Кузайкино (12+)
**09.20** Ретроспективный показ ТК «Луч». Линия судьбы и жизни (12+)
**09.45** Ретроспективный показ ТК «Луч». Вечное наследие Ризы Фахретдина (12+)
**10.00** Ретроспективный показ ТК «Луч». Городской парк (12+)
**10.15** Ретроспективный показ ТК «Луч». Город день за днем (12+)
**10.35 Д/ф «Как создать киборга»** (12+)
**11.30 М/ф «Когда зажигаются елки»** (0+)
**11.50 М/ф «Высокая горка»** (0+)
**12.50** Сельская жизнь (повтор) (12+)
**13.15 М/ф «Машины сказки»** (0+)
**13.20 М/ф «Машины страшилки»** (0+)
**13.35 Д/ф «Горизонт приключений. Крым»** (12+)
**14.30, 04.30 Д/ф «Горизонт приключений. Алтай»** (12+)
**15.25, 05.20 Т/с «Акватория»** (16+)
**16.05, 03.20, 06.00 Т/с «Сватьи-2»** (16+)
**17.05 Д/ф «Горизонт приключений. Алтай»** (12+)
**19.40** Ваш ЛУЧший вечер (12+)
**21.40 Х/ф «Я ненавижу День святого Валентина»** (16+)
**23.15 Х/ф «Драконы Нью-Йорка»** (16+)
**00.50 Д/ф «Золото неизвестных вождей. Курские клады»** (12+)
**01.05 Д/ф «Микульчище. Древний центр великой Моравии»** (12+)
**01.20 Д/ф «Свияжск. Музей археологического дерева»** (12+)
**01.30 Д/ф Цикл «Битва ставок»** (0+)
**02.15** Релакс (16+)

**Җомга, 29 сентябрь**

**07.00**, 12.15, 19.00, 21.00 Новости (12+)
**07.15**, 07.32, 19.12, 19.35, 21.10, 21.25 Прогноз погоды (6+)
**07.17**, 12.30, 19.15, 21.15 Яңалыклар вакыты (12+)
**07.35 Т/с «Фронт»** (12+)
**08.30 Д/ф «Не факт»** (12+)
**09.05** Сладкая жизнь. Кулинарная программа (12+)
**09.30 М/ф «Волшебный клад»** (0+)
**09.45 М/ф «Веселый огород»** (0+)
**09.55 Т/с «Акватория»** (16+)
**12.50 М/ф «Машины страшилки»** (0+)
**12.55 Х/ф «Маленькая принцесса»** (0+)
**14.20 Х/ф «Лейтенант Суворов»** (12+)
**16.05, 03.20, 06.00 Т/с «Смешная жизнь»** (16+)
**17.05, 04.40 Д/ф «Горизонт приключений. Алтай»** (12+)
**18.05 Д/ф «Шаманы Таймыра»** (12+)
**19.40** Ваш ЛУЧший вечер (6+)
**20.00** Җомга (повтор) (12+)
**20.25** Ваш ЛУЧший вечер (6+)
**21.40 Х/ф «Оля + Коля»** (16+)
**23.30 Х/ф «Я ненавижу день святого Валентина»** (16+)
**00.55** Релакс (16+)
**04.15 Д/ф «Не факт»** (12+)
**05.25 Д/ф «Золото неизвестных вождей. Курские клады»** (12+)
**05.45 Д/ф «Свияжск. Музей археологического дерева»** (12+)

**Шимбә, 30 сентябрь**

**07.00** Новости (12+)
**07.15**, 07.32, 16.25, 18.15, 20.35, 22.30 Прогноз погоды (6+)
**07.17** Яңалыклар вакыты (12+)
**07.35 Х/ф «Ты у меня одна»** (16+)
**09.30 Х/ф «Я ненавижу День святого Валентина»** (16+)
**10.45 Д/ф «Горизонт приключений. Алтай»** (12+)
**13.30 Т/с «Убийства в ...»** (16+)
**14.25 Х/ф «Драконы Нью-Йорка»** (16+)
**16.10** Мировые новости (12+)
**16.30 Х/ф «Оля + Коля»** (16+)
**18.20** Елка. Концерт (16+)
**22.05 Х/ф «В лесах Сибири»** (16+)
**22.35 Д/ф «Как создать киборга»** (12+)
**23.30** Ретроспективный показ ТК «Луч» Передача «От всей души» (12+)
**01.20** Релакс (16+)
**04.10 Д/ф «Путешествия в деталях. История Сибири»** (12+)
**05.50** Сладкая жизнь. Кулинарная программа (12+)
**06.15 Х/ф «Маленькая принцесса»** (0+)

**Якшәмбе, 1 октябрь**

**07.48**, 16.10, 17.10, 17.35, 21.25 Погода (6+)
**07.55 Х/ф «Инспектор уголовного розыска»** (0+)
**09.35** Сладкая жизнь. Кулинарная программа (12+)
**10.00 М/ф «Желтый аист»** (0+)
**10.10 М/ф «Хрустальное небо вчерашнего дня»** (12+)
**11.40 Х/ф «Оля + Коля»** (16+)
**13.30 Т/с «Цзюнь Цзюлин»** (16+)
**14.25 Х/ф «В лесах Сибири»** (16+)
**16.15** Ваш ЛУЧший вечер. ЛУЧшее за неделю (6+)
**17.15** Позитивные новости (12+)
**17.40 Х/ф « Моя чужая дочка»** (12+)
**21.30 Х/ф «Ностальгия»** (16+)
**23.30** EMIN. CROCUS Citi Hall. Концерт (16+)
**01.10** Релакс (16+)
**04.00 Х/ф «Ты у меня одна»** (16+)
**05.35 М/ф «Хрустальное небо вчерашнего дня»** (12+)
**02.25 Х/ф «В лесах Сибири»** (16+)

## Җинаять һәм җәза

### Әлмәтле чиркәүдә сумка урлаган

**Урлашуда гаепле дип табылган 63 яшьлек пенсионер хатын-кызга карата җинаять эше кузгатылган.**

Эш материаллары буенча, ул Петр һәм Павел храмында булган вакытта бер хатын-кызның сумкасын урлаган. Анда акча һәм шәхси әйберләр салынган булган. Зыян күрүче үзенә килгән зыянны 12 мең сумга бәяли.

Татарстан прокуратурасы матбугат хезмәте хәбәр итүенчә, пенсионер ханым гаебен танымаган. Аңа 60 сәгать мәҗбүри эш рәвешендә җәза билгеләгәннәр.

### Наркотик төргәкләрен таратучының эзенә төштеләр

**Әлмәттә 16 яшьлек егеткә карата җинаять эше кузгатылды.**

Оператив мәгълүматны тикшергән вакытта хокук саклаучылар Әлмәттә наркотик төргәкләрен таратучы 16 яшьлек егетне тоткарлаганнар. Токарликов урамында оперативниклар наркотик яшерелгән 12 урынны табалар, алардан 22,3 г тыелган матдәләр табып алына.

Егеткә карата «Наркотикларны, психотроп матдәләрне яки аларның аналогларын законсыз җитештерү, сату яки тарату» маддәсе буенча җинаять эше кузгатылган, дип хәбәр итә Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгының матбугат хезмәте.

### Тыелган матдә тараткан өчен тоткарлаганнар

**Әлмәтлене ярты килограмм «синтетика» өчен тугыз ел колониягә хөкем иткәннәр.**

Әлмәт шәһәр прокуратурасы наркотиклар сатарга маташкан 20 яшьлек әлмәтлегә карата гаепләүне хуплады, дип хәбәр итә ТР прокуроры өлкән ярдәмчесе Руслан Галиев.

Җинаять эше материалларына караганда, 15 майдан 29 ына кадәр арада егет билгесез бер кеше белән килешенеп, Әлмәттә яшерен 8 урынга ярты килограммнан артык «синтетика» таратып чыга. Оператив-тикшерү чаралары барышында хокук сагында торучылар әлеге урыннарны ачыклый һәм тыелган матдәне табып ала. Егет үзенең гаебен таный. Аны 9 елга каты режимлы колониягә хөкем итәләр. Бу хакта Татарстан прокуратурасы матбугат хезмәте хәбәр итә.

## Юл һәлакәте

### Әлмәттә 7 яшьлек баланы «зебра»да бәрдерделәр

**17 сентябрьдә кичке бишенче яртыларда Ленин урамындагы 26 нчы йорт каршында юл-транспорт һәлакәте булды.**

Беренчел мәгълүматлар буенча, 32 яшьлек «Опель Астра» автомобиле йөртүчесе, Чехов урамы ягыннан Радищев урамы юнәлешендә хәрәкәт иткәндә, көйләнмәгән җәяүлеләр кичүе буенча юлны аркылы чыгып килүче җәяүлегә өстенлек бирмәгән һәм 2016 елда туган баланы бәрдергән. Бу хакта Россия Эчке эшләр министрлыгының Әлмәт районы буенча бүлегенең ЮХИДИ бүлеге хәбәр итә.

Юл-транспорт һәлакәте нәтиҗәсендә тән җәрәхәтләре алган 7 яшьлек бала хастаханәгә озатылган.

podpiske.pochta.ru

Татарстан Язучылар берлегенең Әлмәт бүлеге оешуга **60 ел**

Факил **Сафин**

# Бишка

(Хикәя)


ФОТО: FREEPIK.COM

« **Башы 35-36 нчы саннарда**

БИШКА дигәндә аның күзләре яктырып китә, йөзләренә алсулык тибеп чыга. Башкалар ничектер, мин моны сизеп торам. Аннан Бишка әйтте, бездә нефть яшь икән әле, тиз генә чыгара башламаслар. Болар эз генә салып куялар икән, тагын икенче якка күчеп китмәкчеләр ди. Бишкасыз нишләрсең инде, үткән атнада бер машина утын кайтарып аударды. И йорт җанлы да инде, ни эшләргә кирәк дип кенә тора!

Озак та үтми, Гришка абый белән Шәрифә апаның икәүләп кич клубка төшеп барганнарын күргәли башладым. Хәтта берсендә... Әйтсәң дә ярый торгандыр инде, абзар артлап кына икесе бергә безнең мунчага кереп киткәннәрен шәйләп калдым. Бу хакта әнкәйгә әйтергә тел кычытса да, курыктым, серне эчкә бикләдем.

Сер дип инде, эчне тишеп бетермәде тагын, чишелде. Бишка белән Шәрифә апа авыл советына барып язылышып кайтканнар икән. Табышканнар болар. Шулай итеп җизниле дә булып куйдым, әмма малай чакның бер хыялы тормышка ашмады: Шәрифә апаны кияүгә алып киткәндә олы капканы үзем ачармын дип йөри идем. Алар исә җәяүләп кенә барганнар да кайтканнар авыл советына. Туйлары да артык шау-шулы булмады ахры. Берничә көннән, Сәхипҗамал әби кереп, әнкәйгә зарланып алды:

- Болай булмый бит инде, никахсыз-нисез, үз өемдә чит кеше тотарга... Әйттем Шәрифәгә, никахсыз яшәүгә бәхиллегем юк, дидем. Бишкасы авыз ерып тик тора, Шәрифә аңлатты инде. «Ничек була соң ул никах, давай ясатып куябыз», ди икән. Шәрифәне дә озак тотмас инде, үзе белән алып китәр. Хатын-кызлар да эшли икән анда, измә болгатып торалар диме. Шәрифә караган да каткан инде шул адәмгә. Сөйләштеләр, чыш-пыш килделәр дә, өйләнешеп тә куйдылар. И и, хәзерге яшьләрне. - Сәхипҗамал түти ишеккә табан бер адым атлагач, кабат әнкәйгә табан борылды. - Әйт әле Мингаярьгә, боларга никах укысын. Бишкасы каршы түгел ди бит.

Әнкәй район газетасын карашырып утырган әткәйгә эндәште.

- Карт, сиңа әйтәм, икенче кавем кешесенә никах укырга ярыймы? Шәрифәбез никахсыз яшәп ята икән бит...

Әткәй риза булмаган тавыш белән әйтеп куйды:

- Яшәрләр инде... Иман калдымыни яшьләрдә. Никахсыз да яшәрләр...

Шул чагында Сәхипҗамал түтигә нидер булды, әткәй каршысына килеп өстәлгә таянды:

- Укы, Мингаярькәем, шуларга никах. Яшәтмә болай Шәрифәне. Үз күз алдында үскән бала бит ул... Мәдрәсә белемең бар, никахка гына җитәр әле.

Әткәй урыныннан торды.

- Никах дигәч тә... Белсәләр, ник туганыңа үкенерсең! Заманы нинди бит. Иман-шәфкать калдымыни бәндәләрдә. Барып әләкләсәләр.

- Беркем дә белмәс, - диде Сәхипҗамал түти, тавышын әкренәйтеп. - Күреп торам, Шәрифә дә бәргәләнә. Әйт, никах өчен ни кирәк?

- Лә иллаһи кәлимәсен әйтергә тиеш бит кияү. Ризамы ул аңа? Безнең халык түгел бит.

- Риза дигән бит инде. Аннан ул гел татарлар арасында үскән, Бөгелмә ягыннан ди. Татарча да аз-маз сукалый. Шәрифә белән чекердәшәләр инде, берсе татарча пупалый, берсе русча.

Кызыгы шул, никах укылганмы, юкмы, анысын мин күрми-белми калдым. Әмма Шәрифә апа бер көнне әткәйгә күлмәклек ситса кертеп чыкты.

- Абзыкай, кылган яхшылыгыңны мәңге онытмам, - диде ул дулкынланып. Минем кулга исә бер уч ирис кәнфите һәм хушбуй аңкып торган чигелгән кулъяулык тоттырды.

...Бик күңелле тормыш башланган иде дә. Шәрифә апа Бишка сүзен теленнән дә төшерми иде. Язмышның үз кануннары: кайдадыр күрше районда эшләп йөргәндә торба ычкынып, Бишканы харап иткән.

Кара кайгы килде Шәрифә апага. Авырлы иде. Озак та үтмәде, тупырдап торган бер малай алып кайтуын хәбәр иттеләр. Бәбине күрше апабыз участок больницасында тапкан иде, берничә көннән Шәрифә апа бәбиен күтәреп өйләренә кайтып керде. Әнкәйгә ияреп мин дә бәби күрергә кердем.

- Бишка! Коеп куйган Бишка! - дип сөйләнә Шәрифә апа бишек тирәсендә. - Бу кадәр Бишка булыр икән, үзе тапса да болай ук булмас!

Әнкәй сәерсенеп, сорап куйды:

- Балаңа Бишка дип исем кушмассың бит инде, Шәрифә? Бишка да Бишка... Шул да булдымы исем.

- Исемен уйлап куйган идек инде без аның, әле әтисе исән чагында ук, - Шәрифә апа күзеннән сыгылып чыккан яшен сөртеп алды. - Дусты булган аның, Данил исемле. Татар малае, шәп егет иде ди. Малай булса, Данил дип кушабыз дип йөргән иде. Кыз турында уйламадык та. Бишка ике сүзнең берендә: «Малайка, малайка», - ди торган иде, мәрхүмкәем.

Данил чая малай булып үсте. Әтисенә охшап, буйчан, әтисенә охшап, йөзеннән елмаю китми.

...Институт тәмамлагач, хәрби кафедра белемен алучы буларак, мине бер елга Ерак Көнчыгышка армия хезмәтенә җибәрделәр. Тынгысыз чагы иде чик буйларының, хезмәт вакыты тәмамлангач та ике-өч ай артык гарнизонда яшәргә туры килде.

Сентябрь урталарында гына авылга кайтып җиттем.

Өй турына җитәрәк, каршыма Шәрифә апа очрады. Башта, барган җиреннән туктап, танымаган сыман минем өске киемнәрне күздән кичерде, аннан ачылып китеп:

- Бәй, бәй, Фәридун түгелме соң син? - диде ул икеләнгәнрәк тавыш белән. - Син армиядә идеңмени? Шаклар катып торам, армиядә икәнеңне искә-санга да алмаганмын. Эштән баш чыкмый бит авыл кешесенең, эш тә эш инде безгә. Күршеңнең армиядә икәнен дә белми яшә инде, вәт бәрәмәч!

Бу сүзләрдән кәефем төште. Ел ярым диярлек армия сафларында айт-двага йөреп кайткан күршеңне шулай каршы ал инде. Хәтта армиядә булуым да мәгълүм түгел авылдашларга. Мин исә ялт-йөлт итекләр киеп, кәс-кәс атлап, хәрби киемнән урамнарны балкытып ашкынып кайтып килгән булам. Алар... белмиләр дә...

Күңел төште.

Шәрифә апа сөйләнүен дәвам итте:

- Кара әле, Фәридун, армия да үстерә алмаган сине. Җыйнак кына егет идең Казанда укып йөргәндә, һаман да шул җыйнак Фәридун икәнсең. Хикмәт диген, армия да үстерә алмый икән адәм баласын. Орлык нинди инде, орлык. Менә безнең Данилны күрсәң! Ике метрлы пәһлеван! Бишка инде, тач әтисе Бишка! Әле сине күргәч, уй килде башыма, минем Бишкага ничегрәк табарлар микән кием-салым. - Күзен чекрәйтеп янә миңа караш ташлады. - Сиңа табылган, син бит җыйнак, минем Бишкага ничек табарлар кием? Аягына кигән итеге дә кырык алтылы бит аның. Әле армияга барганчы тагын күпме үсәр? Бишка инде, Бишка!

...Гомерләр үтә торды. Инде безнең нигездә дә башка кешеләр яши, Шәрифә апаны да, йортларын сатып, Данил Әлмәт якларына алып китте. Башта нефть техникумында укыды, аннан армия сафларында хезмәт итте ул. Беренчеләрдән булып Әфган җиренә аяк баскан солдатлардан булды. Шәрифә апаның чәчләре агарды ул чакта.

- Бишка бит, Бишка, таш арасына яшеренеп калырлык та түгел, ул-бу була калса, иң беренче пуле аны эзләп табачак. Инде исән генә кайтсын.

Намазлык өстеннән төшмәде апабыз. Бәхетенә, кылган догалары кабул булды - Данил исән-имин кайтып керде өенә.

Аннан нефть-газ институтында укып, бүген инде ул шактый зур эштә икән. Начальник ди. Шәрифә апа да гүр иясе булган. Данил-Бишка авылны онытып бетерми икән, әле күптән түгел мәктәпнең түбәсен алыштырткан диделәр. Игелекле Бишка булып үскән, озын гомерле булсын инде.

Зинаида **Захарова**

## Ак бәхетләр телим

Мөлдерәмә бәхет касәм
Балачакта ал иде.
- Үзеңнән калдыра күрмә,
Яшьлегеңә ал, - диде.

Яшьлегемдә яшел иде:
Яраттым яшел төсне.
Яктыртып торды юлымны,
Күкләрдә яшен төсле.

Төсен үзгәртте бәхетем,
Карап ел фасылына.
Җәйләрдә генә төшендем
Яшәүнең асылына.

Көзләремдә бәхетем дә
Киенде гел сарыдан.
Бәхетемә уралыпмы,
Сагышларым сарылган.

Кышларда ул ап-ак булды,
Күрсәң, исең китәрлек.
Ак бәхетләр бирсен Ходай,
Гомереңә җитәрлек.

## Тимә

Нигә диеп, әйтче, усалланып,
Уттай тының аңа өрәсең?
Яклаучысы да юк, бер
мескен ул,
Нигә шулай зәһәр көләсең?

Ә ул белми «шакал»
икәнеңне,
Аңламый ул, ача йөрәген.
Тәкъдиреннән
кыерсытылган ул,
Дөнья аның бирә кирәген.

Ялгышлары, әйе, күп
булгандыр,
Якасыннан алган язмышы.
Көрәшсез дә бирелгән ул
аңа -
Шулдыр аның иң зур
ялгышы.

Бар дөньясы - шомлы
караңгылык,
Тар бүлмәдә үтә төне дә.
Аклык калган бары
күңелендә,
Капшап кына таный
көнне дә.

Бу тормышта азмы
бәхетсезләр?!
Якламый аларны дөнья да.
Тимә аңа! Ул яшәргә тиеш!
Ул яшәргә килгән дөньяга.

podpiska.pochta.ru

«Әлмәт таңнары»
№37 (13564)
**22 сентябрь,** 2023 ел

Яңалыкларны **almet-rt.ru** сайтында һәм социаль челтәрдәге төркемнәребездә укыгыз




(«Акчарлак сканворды»ннан)

## Киңәшләргә колак салыгыз

**Ризык әзерләгәндә кайчак йомырканың сарысын агыннан аерырга кирәк булгалый.**

Моның өчен чынаякка бөрәнкә куегыз да, йомырканы шунда салыгыз. Агы агып төшәр, сарысы калыр. Ә бөрәнкә булмаса, кәгазьдән дә ясый аласыз.

### Инжир югары температураны тиз төшерә

**Температура югары булганда, ангина, бронхит вакытында бер аш кашыгы ваклап туралган инжирга ике стакан кайнар су салып, ун минут сүрән утта кайнаталар.**

Сөзеп алып, көненә дүрт тапкыр эчәләр. Хәлсезлек, арыганлык сизелгәндә, бер стакан җылы сөткә инжир салып эчегез. Инжир баш мие эшчәнлеген дә яхшырта.

### Бәрәңге урынына - гәрчич



**Бәрәңгене алуга гәрчич сибеп куйсагыз яхшы, дип киңәш бирә һәвәскәр бакчачылар.**

Гәрчичне чәчәк аттырырга кирәкми. 15 см үсүгә җирне казырга кирәк (әйләндереп салырга). Бәрәңге үсү чорында җирдәге бөтен ашламаны алып бетерә, ә гәрчич - бәрәңге җире өчен иң яхшысы. Җирне казыгач, фосфор, калий белән туендырырга кирәк. Моның өчен суперфосфат (1 сутый җиргә 200 г), калий сульфаты (1 сутый җиргә 15 г) сибеп чыгарга кирәк. Бергә бутап сибә аласыз. Төрле чирләрдән «Фитоспорин» сибәргә киңәш ителә. Черемә булса, аны кертеп казырга кирәк.

### Гортензияне кайчан һәм ничек кисәргә?



**Аны көзен яфраклары коелып беткәч һәм яз көне - «су эчә башлаганчы» кисәргә кирәк.**

Ботакны тышка таба караган бөре өстеннән кисү шарт. Эчкә таба караганы өстеннән киселсә, ботак үзәккә таба үсәчәк. Гортензияне, куе булмасын өчен, үзәктәге ботагын, шулай ук җиргә авышкан, зәгыйфь ботакларын кисәләр. Нечкәрәк ботакларда - 2 бөре, калганнарында 4 бөре калдырып кыскартыла. Зур үсенте суыкка чыдам була, шуңа күрә кышка ябып калдыруны таләп итми.

## Сканворд җаваплары, 15 сентябрь

| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| М | А | Х | А | О | Н | | А | | Т | А | М | А | Д | А |
| О | | А | | Р | | А | Л | Т | Ы | Н | | Н | | У |
| Т | А | Л | К | А | Н | | М | | Н | А | Н | Т | Е | Р |
| О | | А | | Н | А | Д | А | Н | | | А | | | А |
| Р | И | Т | А | | Г | | | | Җ | Ә | В | И | Т | |
| | О | | Н | | И | | | | А | | Л | | А | Ш |
| Э | Н | Р | И | К | Е | | | | Й | | О | | Р | |
| В | | А | Я | | В | | | | Д | А | Н | Д | И | Н |
| К | И | М | | | | К | А | Р | А | Т | | У | Х | А |
| А | | А | Р | К | А | | Л | | К | А | А | С | | М |
| Л | А | З | Е | Р | | У | К | А | | М | | | | А |
| И | | А | | А | | К | А | Р | Т | А | | | | З |
| П | И | Н | А | Н | Г | | | М | И | | | | | Л |
| Т | | | Н | | А | | Ч | И | Р | | | | | Ы |
| | Г | И | Т | А | Р | А | | Я | | К | У | З | А | К |
| Ш | А | К | И | Р | О | В | А | | А | Р | Ч | А | | |
| А | | | | А | Н | Г | А | Р | | А | | К | Ы | Ш |
| Й | | | | | Н | У | Р | | | Б | Р | И | З | |
| Т | | | | | А | С | Е | Е | В | | И | Р | А | Н |
| А | | | | Ф | | Т | | | А | | М | О | Н | А |
| Н | | А | П | А | С | | | У | С | Т | А | В | | Р |
| | У | Т | | | У | Э | Л | Л | С | | Н | | | |





## Кызыклы дөнья

### Закон каты

**Америка Кушма Штатларындагы Аризона штатында җирле үсемлекләрне саклый торган закон бар.**

Аларга зыян китерү «караклык» дип атала, һәм моның өчен берничә елга төрмәгә ябылу куркынычы яный. Бу - Аризонаның уникаль табигатен саклау өчен шулай эшләнелә.

### Иң күп телле дәүләт

**Папуа - Яңа Гвинея иң күп телле дәүләт булып тора.**

Бередә инглиз теле рәсми тел булып исәпләнсә дә, аны халыкның 1-2 % ы гына куллана. Калганнар барлыгы 820 телдә сөйләшә.

### 5 фактны бел

**Дөнья шулкадәр гаҗәеп һәм кызыклы ки, хәтта теләгән очракта да бөтен кызыкларны белеп бетереп булмас иде. Әгәр сезнең берничә минут буш вакытыгыз булса, бу мәгълүмат сезнең өчен.**

1 Кеше гомере буена биш экваторга тиң ераклык уза.

2 Уртача алганда, кеше җиде минут эчендә йоклап китә.

3 Өч айга кадәр балалар күз яшьләрсез генә елый.

4 Нәкъ менә сезнең туган көнегездә тагын 20 млн лап кеше үзенең туган көнен бәйрәм итә.

5 Өй эшләрен башкарганда кеше бер көнгә уртача 11 км га якын юл уза.

podpiska.pochta.ru





# Авыл халкына - лаеклы тормыш

Габдрахманлыларга чираттагы файдалы бүләк ясалды. Шимбә көнне, 16 сентябрьдә авылда күптән көтелгән чара булды - ремонттан соң сәүдә үзәге ачылды

Яңарыш

Наилә **Әл-Әйюби**

**Сәүдә үзәгенә керү урыны матур итеп бизәлгән, кызыл тасма сузылган, тантаналы музыка яңгырый. Авыл халкын авыл җирлеге башлыгы Ренат Мифтахов белән Әлмәт районы правление рәисе Җәлил Насретдиновлар сәламләде.**

Үз чыгышларында алар яңартылган сәүдә үзәгендә авыл халкы өчен дә, җирле эшмәкәрләр өчен дә уңайлы шартлар тудырылуын билгеләп үттеләр. Авыл өчен бик мөһим булган әлеге инфраструктура объектын ремонтлау эше «СМУ-8» ҖЧҖ көче белән, меценатлар - Тәхаветдиновлар һәм Җәләевләр гаиләләре ярдәмендә башкарып чыгылган.

Тантаналы мизгел - кызыл тасма киселгәннән соң, габдрахманлылар эчкә үттеләр һәм сәүдә үзәгендә булган үзгәрешләрне лаеклы бәяләү өчен икенче катка күтәрелделәр. Икенче каттагы иркен, якты зал заманча павильоннарга бүлгәләнгән, тиздән аларда төрле ассортименттагы товарлар сатучы кибетләр урнашачак. Хәзер авыл кешеләренә кирәкле әйберләрен сатып алу өчен шәһәргә барып йөрергә туры килмәячәк, барысы да якында - үзләренең сәүдә үзәгендә генә булачак.

**Сәүдә үзәге җитәкчесе Руслан Хәлимов хәзерге вакытта арендачылар белән килешүләр төзү процессы баруын билгеләп үтте. Биредә даруханә, төзелеш материаллары, канцелярия товарлары, балалар уенчыклары, киемсалым һәм башка товарлар тәкъдим итүче кибетләр ачылачак.**

Баштагы айларда аренда хакы зур булмаячак, гәрчә алга таба да ул шәһәрдәгегә караганда күпкә түбәнрәк булачак, дип ышандырды ул.

*- Безнең бурыч - авыл халкына кирәкле әйберләрне кулай бәягә сатып алу мөмкинлеге бирү һәм авыл эшмәкәрләре өчен уңайлы шартлар тудыру,* - дип ассызыклады сәүдә үзәге җитәкчесе.

Венера Шәрәфиеваның биредә үз матурлык салоны бар.

*- Хатын-кызларыбызның бары тик сыйфатлы косметика гына куллануларын һәм үз-үзләрен карау буенча безнең хезмәтләрдән файдалана алуларын телим. Без монда ремонтка кадәр дә эшләдек. Чәчтарашханә ачарга планлаштырабыз, яңа процедуралар барлыкка киләчәк. Бездә бәяләр кешеләрне җәлеп итәрлек булачак,* - диде ул.



Эшмәкәр Лилия Баязитова исә сәүдә үзәге ачылуга ук товарларын китергән. Ассортиментта - урын-җир әйберләре, сөлгеләр, өйдә кия торган өс киемнәре һәм башкалар. Авылда яшәүче хатын-кызлар аның товарлары белән шундук кызыксына да башладылар, өс киемнәрен киеп тә карадылар.

***Яңартылган сәүдә үзәгендә авыл халкы өчен дә, җирле эшмәкәрләр өчен дә шартлар бар.***

*- Мондый сәүдә үзәге безгә бик кирәк иде. Бигрәк тә даруханә булуына бик шатбыз. Банкомат та урнаштырылыр дип көтәбез. Безнең Габдрахман иң матур һәм иң төзек авыл, мондый игътибар һәм ярдәм өчен меценатларга рәхмәт. Аллаһы Тәгалә барысына да саулык-сәламәтлек бирсен!* - дип, тәэсирләре белән уртаклашты авылда яшәүче Тәслимә Кәримова.

**Габдрахманда тормыш сыйфаты елдан-ел яхшыра һәм һәр яңа социаль объект авылда яшәүчеләр өчен тагын да күбрәк уңайлыклар һәм тагын да зуррак мөмкинлекләр алып килә.**

podpiska.pochta.ru

